**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию диких кабанов африканской чумой свиней и угрозой ее распространения

В связи с выявлением заболевания диких кабанов африканской чумой свиней на отдельных территориях Заинского района Республики Татарстан, в соответствии со статьями $3^1$, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 31 мая 2016 года № 213 **постановляю**:

1. Установить ограничительные мероприятия (карантин) по африканской чуме свиней на территориях эпизоотических очагов, первой и второй угрожаемых зон, определенных пунктом 2 настоящего Указа, с 29 декабря 2020 года до особого распоряжения.

2. Определить:

а) эпизоотические очаги в пределах следующих отдельных территорий Республики Татарстан:

часть территории, используемой обществом с ограниченной ответственностью «Регион» Багряжского охотничьего хозяйства в Заинском районе, имеющей географические координаты: 55,404216° северной широты и 52,287455° восточной долготы;

часть территории, используемой обществом с ограниченной ответственностью «Карамалинское охотничье хозяйство» в Заинском районе, имеющей географические координаты: 55,289283° северной широты и 51,872807° восточной долготы;

часть территории, используемой обществом с ограниченной ответственностью «Карамалинское охотничье хозяйство» в Заинском районе, имеющей географические координаты: 55,224519° северной широты и 51,766720° восточной долготы;

б) первую угрожаемую зону в пределах административных границ следующих населенных пунктов Республики Татарстан:

деревня Кабан-Бастрык, село Дурт-Мунча, село Пуст-Ашит, село Нижнее Бишево Заинского района;

деревня Перцовка, поселок Кармалка, село Верхние Шипки Заинского района;

деревня Новое Пальчиково, село Нератовка Заинского района, село Верхняя Уратьма Нижнекамского района;

в) вторую угрожаемую зону в пределах административных границ Агрызского, Азнакаевского, Аксубаевского, Актанышского, Альметьевского, Бугульминского, Елабужского, Заинского, Кукморского, Лениногорского, Мамадышского, Менделеевского, Мензелинского, Муслюмовского, Нижнекамского, Новошешминского, Нурлатского, Рыбно-Слободского, Сабинского, Сармановского, Тукаевского, Черемшанского, Чистопольского районов Республики Татарстан, за исключением территорий свиноводческих хозяйств, отнесенных к компартментам III и IV.

3. Запретить:

а) в эпизоотических очагах:

посещение территории посторонними лицами, кроме специалистов органов и организаций, входящих в систему Государственной ветеринарной службы Российской Федерации (далее – специалисты госветслужбы), персонала, привлеченного для ликвидации эпизоотического очага, лиц, проживающих и (или) временно пребывающих на территории, признанной эпизоотическим очагом;

перемещение и перегруппировку животных;

убой всех видов животных, реализацию животных и продуктов их убоя, а также кормов;

въезд (выезд) транспорта, не задействованного в мероприятиях по ликвидации очага африканской чумы свиней и (или) по обеспечению жизнедеятельности людей, проживающих и (или) временно пребывающих на территории, признанной эпизоотическим очагом, на территорию (с территории) эпизоотического очага;

все виды охоты, за исключением охоты в целях регулирования численности охотничьих ресурсов в порядке, установленном Федеральным законом от 24 июля 2009 года № 209-ФЗ «Об охоте и о сохранении охотничьих ресурсов и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»;

иные мероприятия по заготовке дикого кабана на мясо, для изготовления чучел, на иные цели, а также посещение посторонними лицами зараженных и подозреваемых в заражении территорий, заготовку кормов и подстилочного материала для сельскохозяйственных животных;

б) в первой угрожаемой зоне:

вывоз живых свиней, свиноводческой продукции и сырья за пределы первой угрожаемой зоны;

реализацию свиней и продуктов, полученных от убоя свиней, за исключением реализации свиноводческой продукции промышленного изготовления;

закупку свиней у населения, за исключением закупки, производимой в рамках мероприятий по ликвидации очага африканской чумы свиней под контролем специалистов госветслужбы;

заготовку на территории зоны и вывоз из нее мяса свиней, сырья и продуктов свиноводства, отходов свиноводства, оборудования и инвентаря, используемого при содержании свиней;

проведение сельскохозяйственных ярмарок, выставок (аукционов) и других мероприятий, связанных с передвижением, перемещением и скоплением животных;

пересылку, включая почтовые отправления, свиноводческой продукции непромышленного изготовления;

в) во второй угрожаемой зоне:

реализацию свиней и продуктов, полученных от убоя свиней, за исключением реализации продуктов животноводства промышленного изготовления;

проведение сельскохозяйственных ярмарок, выставок (аукционов) и других мероприятий, связанных с передвижением, перемещением и скоплением свиней, кроме случаев, связанных с производственной деятельностью свиноводческих хозяйств, отнесенных к компартментам III и IV и исключенных из второй угрожаемой зоны в соответствии с пунктом 2 настоящего Указа;

закупку свиней у населения;

выгульное содержание свиней, в том числе свиней, содержащихся под навесами;

пересылку, включая почтовые отправления, свиноводческой продукции непромышленного изготовления;

вывоз живых свиней, свиноводческой продукции и сырья, не прошедших промышленной тепловой обработки при температуре выше 70 °С, обеспечивающей их обеззараживание, кроме хозяйств, отнесенных к компартментам III и IV и исключенных из второй угрожаемой зоны в соответствии с пунктом 2 настоящего Указа.

4. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить план мероприятий по ликвидации очага африканской чумы свиней и предотвращению распространения возбудителя болезни на территории Республики Татарстан.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Исполняющий обязанности**
**Президента Республики Татарстан** **А.В. Песошин**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
29 декабря 2020 года
№ УП-912

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында**

Татарстан Республикасы Зәй районының аерым территорияләрендә кабан дуңгызларының Африка дуңгыз чумасы белән чирләве ачыклану һәм аның таралу куркынычы булу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 31 маендагы 213 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм**:

1. Әлеге Указның 2 пункты нигезендә билгеләнгән эпизоотия чыганаклары, куркыныч янаган беренче һәм икенче зоналар территорияләрендә 2020 елның 29 декабреннән аерым боерык чыгарылганга кадәр Африка дуңгыз чумасы буенча чикләү чаралары (карантин) кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Татарстан Республикасының аерым территорияләре чикләрендә эпизоотия чыганакларын:

төньяк киңлекнең 55,404216 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 52,287455 градусы географик координатлары буенча урнашкан Зәй районы Баграж аучылык хуҗалыгының «Төбәк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган территориянең бер өлеше;

төньяк киңлекнең 55,289283 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 51,872807 градусы географик координатлары буенча урнашкан Зәй районының «Карамалы аучылык хуҗалыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган территориянең бер өлеше;

төньяк киңлекнең 55,224519 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 51,766720 градусы географик координатлары буенча урнашкан Зәй районының «Карамалы аучылык хуҗалыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган территориянең бер өлеше;

б) куркыныч янаган беренче зонаны Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары административ чикләре кысаларында:

Зәй районының Кабан-Бастрык авылы, Дүртмунча авылы, Бишсубаш авылы, Түбән Биш авылы;

Зәй районының Перцовка авылы, Кармалка поселогы, Югары Шепкә авылы;

Зәй районының Яңа Пәлчикәү авылы, Нератовка авылы, Түбән Кама районының Югары Уратма авылы;

в) куркыныч янаган икенче зонаны, III һәм IV компартментларга караучы дуңгызчылык хуҗалыклары территорияләреннән тыш, Татарстан Республикасы Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Кукмара, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Тукай, Чирмешән, Чистай районнары административ чикләре кысаларында.

3. Түбәндәгеләрне тыярга:

а) эпизоотия чыганагында:

территориягә, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнар һәм оешмалар белгечләреннән (алга таба – дәүләт ветеринария хезмәте белгечләре), эпизоотия чыганагын бетерү өчен чакырылган персоналдан, эпизоотия чыганагы дип билгеләнгән территориядә яшәүче һәм (яисә) вакытлыча шунда торучы затлардан тыш, чит кешеләр керүне;

хайваннарны күчерүне һәм яңадан төркемнәргә бүлүне;

барлык төр хайваннарны чалуны, хайваннарны һәм аларны чалудан алынган продуктларны, шулай ук терлек азыгын сатуны;

Африка дуңгыз чумасы чыганагын бетерү һәм (яисә) эпизоотия чыганагы дип билгеләнгән территориядә яшәүче һәм (яисә) вакытлыча торучы кешеләрнең тормыш эшчәнлеген тәэмин итү чараларында файдаланылмаган транспортның эпизоотия чыганагы территориясенә (территориясеннән) керүен (чыгуын);

«Ау һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә аучылык ресурслары санын җайга салу максатларында ау оештырудан тыш, ауның барлык төрләре;

кыргый дуңгызны иткә сую, карачкылар әзерләү буенча башка чаралар, шулай ук авыру таралган һәм авыру таралуда шикләнелгән территорияләрдә чит затларның керүе, авыл хуҗалыгы хайваннары өчен азык һәм аслык материаллар әзерләү;

б) куркыныч янаган беренче зонада:

куркыныч янаган беренче зонадан тере дуңгызларны, дуңгызчылык продукциясен һәм чималын чыгаруны;

сәнәгать җитештерүе юлы белән алынган дуңгызчылык продукциясен сатудан тыш, дуңгызларны һәм дуңгыз чалудан алынган продуктларны сатуны;

Африка дуңгыз чумасы чыганагын бетерү чаралары кысаларында дәүләт ветеринария хезмәте белгечләре күзәтчелегендә башкарыла торган сатып алу очракларыннан тыш, халыктан дуңгыз сатып алуны;

эпизоотия зонасы территориясендә дуңгыз ите, дуңгызчылык чималы һәм продуктлары әзерләү һәм аларны, дуңгыз асрау калдыкларын, дуңгыз асраганда файдаланыла торган җиһаз һәм инвентарьларны транспортка төяп территориядән чыгаруны;

хайваннарны күчерү һәм туплау белән бәйле авыл хуҗалыгы ярминкәләре, күргәзмәләр (аукционнар) һәм башка чаралар үткәрүне;

почта аша салуны да кертеп, сәнәгать җитештерүе юлы белән алынмаган дуңгызчылык продукциясен җибәрүне;

в) куркыныч янаган икенче зонада:

сәнәгать җитештерүе юлы белән алынган терлекчелек продукциясен сатудан тыш, дуңгызларны һәм дуңгыз чалудан алынган продуктларны сатуны;

III һәм IV компартментларга караучы һәм әлеге Указның 2 нче пункты нигезендә куркыныч янаган икенче зонага кертелмәгән дуңгызчылык хуҗалыкларының җитештерү эшчәнлеге белән бәйле очраклардан тыш, дуңгызларны күчерү һәм туплау белән бәйле авыл хуҗалыгы ярминкәләре, күргәзмәләр (аукционнар) һәм башка чаралар үткәрүне;

халыктан дуңгыз сатып алуны;

дуңгызларны, шул исәптән төз лапаста тотыла торганнарын, ябылуда тотмыйча асрауны;

сәнәгать җитештерүендә алынмаган дуңгызчылык продукциясен, почта аша салуны да кертеп, җибәрүне;

әлеге Указның 2 нче пункты нигезендә III һәм IV компартментларга караучы һәм куркыныч янаган икенче зонага кертелмәгән дуңгызчылык хуҗалыкларыннан тыш, тере дуңгызларны, 70°С югарырак температурада аларны йогышсызландыруны тәэмин итә торган сәнәгать эшкәртүе узмаган дуңгызчылык продукциясен һәм чималын, транспортка төяп чыгаруны.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә Африка дуңгыз чумасы чыганагын бетерү һәм Татарстан Республикасы территориясендә чирнең таралуын булдырмау чаралары планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 29 декабрь
№ ПУ-912